СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«29» сентябрь 2017ел** **№48**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде: "2018 елда Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә (түләү күләме 200 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

1. Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсәләсе буенча җирле референдум уздыруны 2017 елның 19 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2018 елда Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә (түләү күләме 200 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: Вак таш сатып алу, юл-урам челтәрендәге вак таш һәм юл өслеген урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү.
Шушмабаш авылы: Бакча ур.,Урак һәм Чүкеч ур., Яр буе ур.;.Шекә авылы: Ворошилов ур., Октябрь ур.; Носы авылы Комсомол ур.; Сәрдәбаш авылы: Җиңүнең 65 еллыгы ур., М.Жуков ур.; Илдус авылы Н.Сафин ур.; Үгез-Елга авылы Яшел ур; Ишнарат авылы Ф.Миңнуллин ур.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: Шушмабаш, Шекә, Носы, Сәрдәбаш торак пунктларының санкцияләнмәгән чүплекләре булган урыннарда җир участогын рекультивацияләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп ур., 1б йорт; ТР, Арча районы, Носы ав., Татарстан ур., 45 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ